**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Зур Сукаеш авылы | № 18 | 25 сентябрь 2017 ел.

Сукаеш авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Сукаеш авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Сукаеш авылы башкарма комитетының 11 сентябрь 2017 елда чыккан 15 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Сукаеш авыл җирлеге Советының 11 сентябрь 2017 елда чыккан 15 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сукаеш авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 19 ноябрь 2017 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   “Сез, Сукаеш авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2018 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   1) Авыл җирлеге биләмәсендә электр- җылылык- газ һәм су белән тәэмин иту (аз энергия сарыф итә торган лампалар һәм урам утларына электротоварлар алу, урам утларын карап тоту хезмәте күрсәтү, Түбән Сукаеш авылынынң салкын су челтәренә су үткәргеч трубалары алу);
   2) авыл җирлеге эчендәге юлларны ремонтлау ( авыллар юлларына щебенка җәйдерү
   3) Җирлектә балалар һәм яшьләр белән оештыру һәм чаралар үткәрү өчен (спорт мәйданына уен корылмалары алу һәм урнаштыру);

   РИЗА КАРШЫ

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис: З.Җ.Закирова